КАРАР (РЕШЕНИЕ)

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге составына керүче Байлар Сабасы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

30.11.2021 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 04.10.2019 елның 33 номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында"гы карарына таянып, 2021 елның 30 ноябрендә узган гражданнар җыенында “2022 нче елда “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында, яшәү урыны буенча “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең тротуарларын һәм су агу улакларын төзекләндерү һәм төзү;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең су белән тәэмин итү челтәрен проектлаштыру;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын төзекләндерү;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең һәйкәлләренә кече архитектура формалары һәм фигуралар ясау, аларны урнаштыру;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең тышкы яктырту челтәрләрен реконструкцияләү, капиталь төзекләндерү буенча эшләр башкару;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендәге чишмәләрне, зиратларны төзү, төзекләндерү һәм карап тоту;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә агач һәм куаклар утырту буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 6581 кеше кертелгән, шуның 3357се тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 3243 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 114 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР ИТТЕ:

1. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. “2022 нче елда “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында, яшәү урыны буенча “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең тротуарларын һәм су агу улакларын төзекләндерү һәм төзү;

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең су белән тәэмин итү челтәрен проектлаштыру;

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын төзекләндерү;

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең һәйкәлләренә кече архитектура формалары һәм фигуралар ясау, аларны урнаштыру;

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең тышкы яктырту челтәрләрен реконструкцияләү, капиталь төзекләндерү буенча эшләр башкару;

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендәге чишмәләрне, зиратларны төзү, төзекләндерү һәм карап тоту;

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә агач һәм куаклар утырту” карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча һәм җирлектә урнашкан мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Саба шәһәр
җирлеге башлыгы

Р.М. Хәсәнов